ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Балык Бистәсе штп.

30.12.2020 №207пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясе турында

“Бөтенроссия халык санын алу турында” 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте комиссиясен төзү турында” 2017 елның 29 сентябрендәге 1185 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясен төзергә.

2. Кушымта итеп бирелә торган

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясе турында Нигезләмәне;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясе составын

РАСЛАРГА.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясе турында” 2019 елның 16 октябрендәге 165пг номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Башлык И.Р. Таҗетдинов

ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2020 елның 30 декабрендәге
207пг номерлы карары
белән расланды

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча Комиссия турында Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясе (алга таба – Комиссия) 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары гамәлләрен координацияләү (яраштыру) өчен оештырылды.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте башкарма органнары территориаль органнарының 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү, үткәрү, нәтиҗәләрен эшкәртү һәм бастырып чыгару (игълан итү) буенча килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләрне оператив рәвештә хәл итү.

Үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен комиссия:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүнең һәм уздыруның барышына контрольлек итүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуга әзерлек һәм аның оператив нәтиҗәләре турындагы мәсьәләне карый;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрүнең оештыру планын раслый;

түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне карый:

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру эшенә төрле оештыру-хокукый рәвешләрдәге оешмаларны җәлеп итү;

тиндәшле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче гражданнарны халык турында мәгълүматлар җыюга, шулай ук халык турындагы мәгълүматларны эшкәртүгә җәлеп итүне оештыру;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен тормышка ашыру:

халык турында мәгълүматлар җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы җиһазлар һәм элемтә чаралары белән җиһазландырылган саклана торган биналар белән тәэмин итү;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклап тору өчен сакланыла торган биналар белән тәэмин итү;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү өчен кирәкле транспорт чаралары, элемтә чаралары бирү;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү өчен кирәкле картографик материалларны (шәһәр һәм авыл җирлекләренең схематик планнарын, административ районнар карталарын) ачыклау;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү эшләрен башкару өчен аларның ресурсларын һәм биналарын файдалану максатыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрен җәлеп итү, шул исәптән халыкның интернет-сан алуда катнашу өчен Бердәм дәүләт хезмәтләре порталына керү мөмкинлеге бирү;

халык турында мәгълүматлар җыючы затларның иминлеген тәэмин итүне, 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләренең һәм башка документларының сакланышын тәэмин итүне оештыру;

гражданнарның торак комплексларының, яшелчәчелек коммерциягә карамаган берләшмәләренең ябык территорияләренә һәм башкаларга керүне тәэмин итүне оештыру;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуга кагылышлы басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар бүлеп бирү;

Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм җирле үзидарә органнарын “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында халык санын алуда катнашуга җәлеп итүгә булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары тарафыннан шәһәр һәм авыл торак пунктларында торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча, корылма төрен (торак яки торак булмаган) һәм әлеге корылма аның балансында булган оешма, предприятие атамасын күрсәтеп, билгеләнгән тәртиптә мәгълүматлар тапшыру; торак биналар саны турында һәм адреслар исемлекләрен актуальләштерү һәм оештыру планнарын төзү өчен яшәү яки булу урыны буенча торак урыннарында яшәүче һәм теркәлгән затлар саны хакында мәгълүматлар бирү;

Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбен гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары бүлекчәләре; торак, торак-эксплуатация оешмалары, идарәче оешмалар һәм компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативларының идарә органнары; вазыйфаи затлары дәүләт, муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннары буенча (фатирлар буенча карталар, йорт (фатир) кенәгәләре) халыкны теркәү исәбен алып баруны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тарафыннан “Бөтенроссия халык санын алу турында” 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ

номерлы Федераль законның 6 маддәсенең 3 пункты нигезендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәлгән затлар турында административ мәгълүматлар бирү;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуга әзерләнү һәм уздыру вакытында мәгълүмати-аңлату эшләре үткәрүне оештыру;

2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашкан физик һәм юридик затларны бүләкләүне оештыру.

4. Комиссия хокуклы:

үз утырышларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары вәкилләреннән 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында мәгълүматын тыңларга;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнарына 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

Комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм дини оешмалар, шулай ук гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итәргә;

Комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү өчен эшче төркемнәр булдырырга.

Комиссия комиссиянең рәисеннән, комиссия рәистәше, комиссия рәисе урынбасары, комиссия әгъзаларыннан һәм аның сәркатибеннән тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышларының еллык планнарын раслый һәм комиссия составын яңарту турында тәкъдимнәр кертә. Комиссия утырышларын комиссия рәисе үткәрә. Комиссия рәисе булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча рәис вазыйфаларын комиссия рәистәше башкара.

5. Комиссия утырышлары ярты елга бер тапкырдан да ким үткәрелми, 2021 елда – еллык эш планнары нигезендә өч тапкыр уздырыла. Комиссия утырышы аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге булган очракта хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары аның утырышларында алмаштыру хокукыннан башка катнаша. Комиссия әгъзалары һәм чакырылган кешеләр докладлар һәм өстәмә докладлар белән чыгыш ясый, фикер алышуларда катнаша, тәкъдимнәр кертә, фикер алышына торган мәсьәләләрнең асылы буенча белешмәләр бирә алалар.

6. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы карарын (хәл итүен) таләп итә торган мәсьәләләр буенча Комиссия билгеләнгән тәртиптә тиешле тәкъдимнәр кертә.

7. Комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм итү максатларында төзелгән комиссияләр өчен мәҗбүри була.

8. Комиссия эшчәнлеген туктату турындагы карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы тарафыннан кабул ителә.

9. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Казан шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлеге (Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында) белән берлектә (килешенү буенча) гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2020 елның 30 декабрендәге
207пг номерлы карары
белән расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча район комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанова Фирдания Гомәр кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәистәше (килешенү буенча) |
| Токранов Вячеслав Иванович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешенү буенча) |
| Зәйнуллина Гөлнара Хәбибрахман кызы | Балык Бистәсе муниципаль районы буенча 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алу буенча вәкаләтле вәкил, комиссия сәркатибе (килешенү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Җамалиев Рөстәм Рәсим улы | Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе |
| Шелкова Светлана Александровна | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Билалова Мәгъмүрә Кыям кызы | Казан шәһәрендә (Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында) дәүләт статистикасы бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешенү буенча) |
| Мингалиев Марат Зиннур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| Ногманова Илсөя Мәлик кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| Вафин Фәрит Мансур улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешенү буенча) |
| Сафиуллин Нурислам Васыйл улы | Татарстан Республикасы буенча КФҮ ДБУнең Балык Бистәсе филиалы бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Ананьева Луиза Рашат кызы | «Сельские горизонты» - “Авыл офыклары” район газетасының баш мөхәррире (килешенү буенча) |
| Хәкимуллин Айрат Альберт улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |

Балык Бистәсе муниципаль районының территориальлек буенча авыл җирлекләре башлыклары һәм шәһәр җирлеге җитәкчесе (килешенү буенча).